ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 26.09.2024 КАРАР
1474

2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнгать - эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасынын балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Кушымта итеп бирелгән Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,75 күләмендә (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.09.2024
1474

карарына 1 нче кушымт

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга елга, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өч еллык уку вакыты | Дурт еллык уку вакыты | Биш еллык уку вакыты | Жиде еллык уку вакыты | Башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 78 737 | 89 952 | 115 527 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 83 699 | 95 607 | 122 722 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 41 684 | | 37 010 | 88 817 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 44 232 | | 39 296 | 94 291 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 87 814 | 72 312 | 265 068 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 93 401 | 76 913 | 281 919 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 36 926 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 39 265 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 80 741 | 77 524 | 124 555 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 85 893 | 82 475 | 132 470 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 121 586 | | 116 554 | | 191 128 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 129 245 | | 123 915 | | 203 145 |
| Театр сәнгате | шәһәр | 62 682 | | 58 352 | 58 267 | 87 898 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | җирлеге | | | | | |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 66 606 | | 62 016 | 61 926 | 93 302 |